КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 апрель г.Казань № 503

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 859 нчы карары белән расланган Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 859 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 сентябрь, 963 нче; 2022 ел, 15 декабрь, 1340 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган

оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия Министрлык тарафыннан субсидия алучыларның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына тигез өлешләрдә түбәндәгечә күчерелә:

агымдагы финанс елының беренче хисап чорында – килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә;

агымдагы финанс елның алдагы хисап чорларында – бу Тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән хисап чоры өчен хисап бирелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин